**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ
24.01.2018**

**КАРАР
№ 235**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре тарафыннан түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Федераль законнар: «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 15 августындагы 706 номерлы карары, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының «Өстәмә белем бирү программалары буенча белем алу турында шартнамәнең якынча формасын раслау хакында» 2013 елның 25 октябрендәге 1185 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының «Гражданнар һәм юридик затлар өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә карый торган хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен түләүне билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре тарафыннан түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләренең түләүле белем бирү хезмәт күрсәтүләренә тарифлар формалаштыру тәртибен (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф

учреждениеләрендә түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифлар турында нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 11 сентябрендәге 1725 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru веб адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Хөснетдинов

1 нче кушымта
«Расланды»
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018
елның 24 гыйнварындагы 235
номерлы карары белән

# БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ТАРАФЫННАН ТҮЛӘҮЛЕ БЕЛЕМ БИРҮ ХЕЗМӘТЛӘРЕ КҮРСӘТҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү турында әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 15 августындагы 706 номерлы карары, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының «Өстәмә белем бирү программалары буенча белем алу турында шартнамәнең якынча формасын раслау хакында» 2013 елның 25 октябрендәге 1185 номерлы боерыгы нигезендә эшләнде.

1.2. Нигезләмә төп белем бирү программасыннан тыш, өстәмә гомуми белем бирү (гомуми үстерү) программаларын, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүче «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - Мәгариф бүлеге) карамагындагы муниципаль мәгариф оешмалары (алга таба - мәгариф оешмалары) тарафыннан түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыруга һәм күрсәтүгә бердәй якын килү урнаштыру максатларында кертелә.

1.3. Нигезләмә түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү турындагы шартнамәләр буенча биремнәр һәм физик һәм (яисә) юридик затлар акчалары исәбеннән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала, шулай ук аларның бәясен булдыруны билгели.

1.4. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр:

Заказчы - үзе яисә башка затлар өчен шартнамә нигезендә түләүле белем бирү хезмәтләренә заказ бирергә ниятләре булган физик һәм (яисә) юридик зат ;

Башкаручы - белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм өстәмә гомуми белем бирү (гомуми үстерү) программаларын, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп

гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча белем алучыларга, укыту планнары кысаларыннан тыш, түләүле уку-укыту хезмәтләре күрсәтүче муниципаль белем бирү оешмасы:

Төп белем бирү программасы - муниципаль биремне үтәү кысаларында күрсәтелә торган мәгариф хезмәтләре, аны финанс белән тәэмин итү бюджет акчалары исәбеннән башкарыла;

Түләүле белем бирү хезмәтләренең кимчелеге - түләүле белем бирү хезмәтләренең я законда каралган яисә аның белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри таләпләргә туры килмәве, яисә шартнамә шартларына (гадәттә куела торган таләпләргә шартлар булмаганда яисә тулы булмаган очракта), яисә түләүле белем бирү хезмәтләре гадәттә кулланыла торган максатларга, яисә килешү төзегәндә, алар турында заказчы тарафыннан башкаручыга хәбәр ителгән, шул исәптән аларны белем бирү программаларында (белем бирү программасының бер өлешендә) каралган тулы күләмдә үтәлмәгән максатларга туры килмәве;

Укучы - түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамә буенча белем бирү программасын үзләштерүче физик зат;

Түләүле белем бирү хезмәтләре - белем алуга кабул иткәндә төзелә торган мәгариф турындагы шартнамәләр буенча физик һәм (яисә) юридик затлар акчалары исәбеннән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру (алга таба - шартнамә);

Түләүле белем бирү хезмәтләренең сизелерлек кимчелеге - чамадан тыш чыгымнарсыз яисә вакыт чыгымнарыннан башка бетерелә алмый торган яисә берничә тапкыр ачыклана торган, яки аны бетергәннән соң яңадан ачыклана торган кимчелекләр яки башка шундый җитешсезлекләр.

1.5. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ буйсынуындагы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының барлык муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

1.6. Түләүле белем бирү хезмәтләре дәүләт һәм муниципаль бюджетлардан бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанслар белән тәэмин ителә торган белем бирү эшчәнлеге кысаларында һәм аңа алмашка күрсәтелә алмый.

## 2. Түләүле мәгариф хезмәтләре төрләре һәм шартнамәләр төзү тәртибе

2.1. Түләүле белем бирү хезмәтләренең күләме һәм шартнамәдә аларның бәясе Башкаручы һәм Заказчы арасындагы килешү буенча билгеләнә.

2.2. Заказчы белән шартнамә һәр конкрет очракта шәхсән, билгеле бер срокка төзелә һәм түбәндәгеләрне күздә тота: хезмәт күрсәтүнең исеме, характеры, хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең күләме һәм шартлары, хезмәт күрсәтүнең кабатлылыгы һәм сроклары, үзара килешеп торучы якларның хокуклары һәм бурычлары, шартнамәне үзгәртү һәм өзү тәртибе, бәхәсләрне хәл итү тәртибе, аерым шартлар. Килешү чоры дәвамында укыту бәясе буенча шартнамәгә өстәмә килешүләр төзү мөмкин. Килешү хисап документы булып тора һәм белем бирү оешмасында кимендә биш ел сакланырга тиеш.

2.3. Башкаручы соратып алына торган түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтү мөмкинлеге булганда Заказчы белән шартнамә төзи һәм шартнамә төзүгә карата Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган очраклардан тыш нинди дә булса физик яисә юридик затка өстенлек күрсәтергә хокуклы түгел.

2.4. Заказчының (укучының) теләге буенча, түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү йомгаклары буенча Башкаручы, укыту предметлары яисә дисциплиналары буенча уку сәгатьләре санын күрсәтеп, уку-укыту программасын, уку циклын яисә предметны (предметларны) күрсәтә торган белешмә бирә.

2.5. Килешү буенча түләү, Заказчы тарафыннан түләү документларында күрсәтелгән Башкаручының шәхси счетларына күчерү юлы белән, акчасыз рәвештә башкарыла.

3. Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүне оештыру

3.1. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү өчен, әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә санап кителгән шартлар булганда, мәгариф оешмасына түбәндәгеләр кирәк:

3.1.1. Түләүле белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗны өйрәнергә һәм укучыларның күздә тотыла торган контингентын билгеләргә.

3.1.2. Түләүле белем бирү хезмәтләренең һәр төре буенча белем бирү программасын, уку планнарын, дәресләр расписаниесен эшләргә һәм расларга. Түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүгә һәм Заказчыга тәкъдим ителә торган сәгать саны. Түләүле белем бирү хезмәтләре төрләре заказчының яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләренә туры килергә, шулай ук муниципаль биремне үтәү кысаларында гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлегенә зыян китермәскә тиеш. Аерым очракларда Заказчының теләге буенча, аның мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен исәпкә алып, индивидуаль уку планы эшләнергә мөмкин.

3.1.3. Заказчы тарафыннан түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәткәндә кирәкле документлар бирүгә карата таләпләрне билгеләргә: Заказчының гаризасы, тиешле медицина бәяләмәләре (түләүле белем бирү хезмәтләренең кайбер төрләре өчен, хореография, спортның аерым төрләре), белем бирү дәрәҗәсе турында документлар, Заказчының шәхесен таныклаучы документ. Укучы 14 яшькә җитмәгән очракта, аның исеменнән гаризаны ата-анасы (законлы вәкиле) бирә.

3.1.4. Түләүле белем бирү хезмәтләренең укыту программасы буенча уку сәгатьләре саныннан, укыту планыннан, түләүле белем бирү хезмәтләренә расланган тарифлардан чыгып, һәр түләүле хезмәткә айлык бәясен исәпләп чыгарырга.

3.1.5. Түләүле белем бирү хезмәтләрен алырга теләгән Заказчыдан кирәкле документларны алырга һәм аның белән түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә шартнамә төзергә (алга таба - килешү). Килешү төзегән вакытта укучы 14 яшькә җитмәгән очракта, аның мәнфәгатьләрендә шартнамәне ата-анасы (законлы вәкиле) төзи.

3.1.6. Түләүле белем бирү хезмәтләренең конкрет төрләрен күрсәтүне оештыру, шул исәптән әлеге хезмәтләр күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең кадрлар составы, оештыру-методик һәм хезмәт күрсәтү функцияләрен үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү, педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен бүлү, шөгыльләр өчен бүлмәләрне билгеләү, белем бирү программасын, уку планын, дәресләр расписаниесен раслау, башка шартларны һәм критерийларны – белем бирү оешмасы теләге буенча, билгеләү турында боерык чыгарырга.

3.1.7. Оешма хезмәткәрләре, шул исәптән төп эштән буш вакытларында түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү буенча бурычларын үтәргә теләк белдергән ике эш башкаручылар белән сроклы хезмәт шартнамәләрен рәсмиләштерергә,

түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүдән алынган акчалар хисабына педагогик хезмәткәрләрне тарификацияләүне гамәлгә ашырырга. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү өчен Башкаручы башка оешмалардан түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алына торган акчалар исәбеннән түләүле граждан-хокукый шартнамәләр төзү юлы белән белгечләрне җәлеп итәргә мөмкин.

3.1.8. Төп белем бирү эшчәнлеген тиешле бюджет акчалары исәбеннән алып баручы педагогик хезмәткәрләрнең һәм түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүче педагогик хезмәткәрләрнең эш вакытын аерым исәпкә алуны оештырырга.

3.1.9. Муниципаль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган төп белем бирү эшчәнлегенә бәйле матди чыгымнарны һәм түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтүгә бәйле матди чыгымнарны аерым исәпкә алуны оештырырга.

3.1.10. Башкаручы Заказчыга «Кулланучылар хокукларын яклау турында» РФ Законында һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда каралган тәртиптә һәм күләмдә түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү турында белешмәләр булган мәгълүматны җиткерергә тиеш.

3.2. Башкаручы Заказчы таләбе буенча танышу өчен түбәндәгеләрне бирергә тиеш:

- мәгариф оешмасының уставы;

- белем бирү оешмасын гамәлгә куючы турында белешмәләр;

- түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүгә шартнамә үрнәге;

- Башкаручы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар расланган документлар;

- шартнамәгә һәм тиешле белем бирү хезмәтенә караган башка белешмәләрне Заказчы үтенече буенча.

Әлеге мәгълүмат исемлеге тулы түгел.

Башкаручы Заказчыга шартнамәгә һәм белем бирү хезмәтенә кагылышлы теләсә нинди белешмәләрне хәбәр итә. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә Башкаручы мәҗбүри тәртиптә хезмәтне күрсәтүче конкрет затны, әгәр бу хезмәт күрсәтү сыйфаты өчен әһәмияткә ия булса, аның турында мәгълүмат бирергә тиеш.

3.3. Түләүле белем бирү хезмәтләре турында мәгълүмат мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы администрациясенең, мәгариф оешмаларының Интернет челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла. Заказчыга мәгълүматны җиткерү ысуллары: белдерүләр, буклетлар, проспектлар, иң яхшы укучылар эшләре, укытучыларның класстан тыш эшләве һ.б. булырга мөмкин.

3.4. Башкаручы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркемгә мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш:

- Заказчы акчалары исәбеннән мәгариф турында шартнамәләр буенча гамәлгә ашырыла торган мәгариф программалары буенча белем алучыларның саны турында;

- белеме дәрәҗәсен, квалификациясен һәм эш тәҗрибәсен күрсәтеп, турыдан-туры түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле педагогик хезмәткәрләрнең персональ составы турында;

- белем бирү оешмасының түбәндәге локаль норматив актларын:Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү һәм аларны күрсәтү нәтиҗәсендә алынган акчаларны тоту тәртибе, шул исәптән түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү турында

шартнамә үрнәге һәм һәр түләүле белем бирү хезмәте (программа) буенча тарифларны раслау турында документ.

3.5. Белем бирү оешмасы түләүле белем бирү хезмәтләренең һәр төре буенча белем бирү оешмасы җитәкчесе раслаган дәресләрне календарь-тематик планлаштыру белән белем бирү программаларына ия булырга тиеш.

3.6. Белем бирү оешмасы Заказчының гомерен һәм сәламәтлеген саклауны гарантияли торган СанПиН 2.4.2.2821-10, 2.4.3049-13, 2.4.4.3172-14 таләпләре нигезендә төп белем бирү эшчәнлеген кысмыйча түләүле белем бирү хезмәтләрен сыйфатлы итеп күрсәтүгә шартлар тудыруга ярдәм итә торган тиешле матди-техник, уку базасына ия булырга тиеш. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү өчен мәгариф оешмасының уку һәм башка биналарын муниципаль хезмәт күрсәтүгә муниципаль бирем нигезендә үткәрелә торган төп белем бирү эшчәнлеге кысаларында уку дәресләре расписаниесендә каралмаган сәгатьләрдә кулланырга рөхсәт ителә.

3.7. Белем бирү оешмасы уставында түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү мөмкинлеге, аларны бирү тәртибе мәҗбүри тәртиптә күрсәтелә.

3.8. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен мәгариф оешмасы түбәндәге локаль актлар әзерли:

3.8.1. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү һәм аларны бирүдән алынган акчаларны тоту турында нигезләмә (түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәткән өчен түләү буенча ташламалар бирелгән очракта, ташламалар бирү исемлеге, күләмнәре һәм тәртибе күрсәтелергә тиеш).

3.8.2. Белем бирү оешмасы җитәкчесенең мәгариф идарәсе башлыгы белән килештерелгән, түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру турында (күрсәтелүче хезмәтләрнең исемлеген һәм төрләрен күрсәтеп, кулланучылар өчен һәр хезмәт төренең хакы, төркемнәр саны һәм белем алучылар, уку сәгатьләре саны, хезмәт күрсәтүләрне оештыруга җаваплы вазыйфаи затлар, һәр хезмәт күрсәтү төре буенча дискриминация коэффициентлары күрсәтелеп) боерыгы.

3.8.3. Һәр түләүле белем бирү хезмәте буенча тарифны исәпләп чыгару.

3.8.4 Муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесе раслаган белем бирү программалары, укыту планнары, дәресләр расписаниесе.

3.8.5. Түләүле белем бирү хезмәтләрен турыдан-туры күрсәтүче һәм аларны күрсәтү шартларын тәэмин итүче хезмәткәрләрнең (административ, техник персонал) штат расписаниесе.

3.8.6. Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү белән шөгыльләнүче мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмә яисә мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмәнең өстәмә бүлеге.

3.8.7. Мәгариф оешмасы хезмәткәрләрен түләүдән алынган акчалар исәбеннән стимуллаштыру түләүләре һәм (яисә) бүләкләү турында нигезләмә.

3.8.8. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алынган керемнәр белем бирү оешмасының Финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

4. Түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар формалаштыру һәм түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алынган акчаларны тоту

4.1. Түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар, кирәкле салымнар һәм җыемнар түләүне исәпкә алып, һәр түләүле белем бирү хезмәте буенча икътисадый

нигезләнгән үзкыйммәт нигезендә, шулай ук белем бирү процессын һәм белем бирү оешмасының матди базасын үстерү һәм камилләштерү мөмкинлеге нигезендә төзелә.

Түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар формалаштыру түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар формалаштыру Тәртибе (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта) нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифны исәпләү рәвеше кушымта итеп бирелгән форма нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта).

Түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар чираттагы елга исәпләнә һәм уку елы дәвамында яңадан каралмый.

4.3. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алынган акчаларны тоту мәгариф оешмасының бюджет мәгариф оешмалары өчен «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ тарафыннан расланган финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүдән алынган акчалар (алга таба - алынган керем) түләүле белем бирү хезмәт күрсәтүләренә тарифлар исәбендә кабул ителгән чыгымнар нигезендә бүленә.

4.5. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе белән бухгалтерлык исәбен алып бару турындагы шартнамә нигезендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУенә түләүле белем бирү эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле документларны тапшыра.

4.6. Түләүле мәгариф хезмәтләре заказчылары тарафыннан түләү кредит оешмалары аша акчасыз башкарыла.

5. Якларның җаваплылыгы һәм түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыруны һәм күрсәтүне контрольдә тоту

5.1. Башкаручы түләүле белем бирү хезмәтләрен шартнамә, устав, белем бирү оешмасының лицензиясе, әлеге Нигезләмә, түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүне оештыруда җайга сала торган локаль норматив акт белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда күрсәтә.

5.2. Башкаручы һәм Заказчы Шартнамәдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Килешүдә һәм Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылык тота.

5.3. Башкаручы үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү җиңеп чыга алмаслык сәбәпләр аркасында, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка нигезләр буенча килеп чыккан дип исбат итсә, түләүле белем бирү хезмәтен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

5.4. Күрсәтелгән түләүле белем бирү хезмәтләренең җитешсезлеге ачыкланганда, шул исәптән аларны белем бирү программаларында (белем бирү программасының бер өлеше) һәм уку планнарында каралганнан тулы күләмдә күрсәтмәгәндә, Заказчы үз сайлавы буенча таләп итәргә хокуклы:

- белем бирү программалары, уку планнары һәм шартнамә нигезендә түләүле белем бирү хезмәтләрен тулы күләмдә түләүсез күрсәтү;

- күрсәтелгән түләүле белем бирү хезмәтләренең хакын тиешле дәрәҗәдә киметү;

- түләүле белем бирү хезмәтләренең үз көчләре яисә өченче затлары тарафыннан кимчелекләрен бетерү буенча аларга тотылган чыгымнарны каплау.

5.5. Заказчы шартнамәне өзәргә һәм зыянны тулысынча каплауны таләп итәргә хокуклы, әгәр шартнамәдә билгеләнгән вакыт эчендә түләүле белем бирү хезмәтләренең кимчелекләре бетерелмәсә. Әгәр аларга түләүле белем бирү хезмәтләренең шактый кимчелеге яисә килешү шартларыннан башка җитди чигенүләр табылса, Заказчы шулай ук шартнамәне үтәүдән баш тартырга хокуклы.

5.6. Әгәр дә башкаручы түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү вакытын (түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүне башлау һәм (яисә) тәмамлау һәм (яисә) түләүле белем бирү хезмәтен күрсәтүнең арадаш вакытын бозган булса) йә түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү вакытында аларның вакытында гамәлгә ашырылмаячагы күренеп торса, Заказчы үз сайлавы буенча хокуклы:

- Башкаручыга яңа срок билгеләргә, аның дәвамында Башкаручы түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүгә керешергә һәм (яисә) түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүне төгәлләргә тиеш;

- өченче затларга акыллы бәя өчен түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүне һәм тотылган чыгымнарның кайтарылуын таләп итүне йөкләргә;

- түләүле белем бирү хезмәтләренең хакын киметүне таләп итәргә;

- Шартнамәне өзәргә.

5.7. Заказчы түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүнең башлану һәм (яисә) тәмамлану срокларын бозып, шулай ук түләүле белем бирү хезмәтләренең кимчелекләренә бәйле рәвештә үзенә китерелгән зыянны тулысынча каплауны таләп итәргә хокуклы.

5.8. Башкаручы инициативасы буенча Шартнамә бер яклы тәртиптә түбәндәге очракларда өзелә:

- 15 яшькә җиткән укучыга дисциплинар түләтү чарасы буларак куылу кулланылганда;

- түләүле белем бирү хезмәтләре бәясен вакытында түләмәү;

-укучының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәү мөмкин булмавы.

5.9. Заказчының тәкъдим ителә торган түләүле белем бирү хезмәтләреннән баш тартуы аңа белем бирү оешмасының Башкаручы тарафыннан бюджет ассигнованиеләре исәбеннән күрсәтелә торган төп белем бирү хезмәтләренең күләме кимүгә сәбәп була алмый.

5.10. Заказчик һәм Башкаручы арасында барлыкка килә торган дәгъвалар һәм бәхәсләр якларның килешүе буенча ирекле тәртиптә хәл ителә, килешүгә ирешмәгәндә - Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә хәл ителә.

5.11. Мәгариф оешмалары җитәкчеләре шәхси җаваплылык тоталар:

- түләүле мәгариф хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә гамәлдәге норматив хокукый актларны, кулланучылар хокукларын яклау турындагы законнарны, шулай ук мәгариф оешмасында түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәткәндә граждан, хезмәт, административ һәм җинаять законнарын үтәү өчен;

- түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру һәм аларның сыйфаты өчен;

- түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүдән алынган акчаларны максатчан файдалану өчен;

- түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәткәндә бәяләр дисциплинасын үтәү өчен;

- Россия Федерациясе законнарында каралган башка гамәлләр өчен.

5.12. Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәткәндә билгеләнгән таләпләр бозылган очракта мәгариф оешмасы, оешма җитәкчесе, хокук бозуда гаепле хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылырга мөмкин.

Административ һәм (яисә) дисциплинар җаваплылык чаралары салу мәгариф оешмасын, оешма җитәкчесен һәм гаепле затларны җибәрелгән хокук бозуларны бетерүдән һәм китерелгән зыянны каплаудан азат итми.

5.13. Әлеге Нигезләмәнең үтәлешен, түләүле белем бирү хезмәтләренең хакын һәм аларны күрсәтүнең сыйфатын контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башкара.

5.14. Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү буенча мәгариф оешмасы эшендә хокук бозулар ачыкланган очракта, шул исәптән аларның сыйфаты кимү, мәгариф оешмасының төп эшчәнлегенә зыян килү очрагында, Мәгариф бүлеге хокуклы:

- түләүле белем бирү хезмәтләрен әлеге мәсьәләне суд тәртибендә хәл итүгә кадәр туктатып торырга.

5.15. Белем бирү эшчәнлеген алып бару хокукына лицензия биргән органга белем бирү оешмасын Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы норматив хокукый актларын бозып гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төренә лицензиядән мәхрүм итү турында үтенечнамә бирергә.

2 нче кушымта

«Расланды»
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018
елның 24 гыйнварындагы 235
номерлы карары белән

**ТҮЛӘҮЛЕ БИРЕМ ХЕЗМӘТЛӘРЕНӘ ТАРИФЛАР ФОРМАЛАШТЫРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ИСӘП-ХИСАБЫ**

Түләүле белем бирү хезмәтләренә тарифлар формалаштыру белем бирү учреждениесенең түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүгә чыгымнарын тулысынча каплау принцибына нигезләнгән, бу вакытта бәя хезмәт күрсәтүләргә тотылган ресурслар нигезендә төзелә.

Түләүле белем бирү хезмәтләренең хакын бер укучыга исәпләгәндә, түләүле мәгариф хезмәтләренең әлеге төреннән файдаланучыларның санытүбәндәгеләр ярдәмендә билгеләнә:

- белем бирү учреждениесенең тулылануы (төркемнәре, класслары һ.б.) нигезендә исәпләнгән түләүле белем бирү хезмәтләренең әлеге төре буенча укучыларның мөмкин булган максималь саны;
- түләүле белем бирү хезмәт күрсәтүләренең әлеге төре буенча планлаштырылган укучылар саны;
- үткән чорда укыганнар саны.

Түләүле белем бирү хезмәтенең бәясе бер кулланучыга (Сун) исәпләгәндә түләүле белем бирү хезмәтләренең тиешле төре буенча чыгымнарның гомуми суммасын түләүле белем бирү хезмәтләренең әлеге төреннән файдаланучыларның гомуми санына бүлүдән өлеш буларак билгеләнә (К).

$$Сун = Су / К$$

Түләүле белем бирү хезмәте (Су) бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Су = Сс + Ну + Ср,$$ монда:

Сс – түләүле белем бирү хезмәтләренең үзкыйммәте;

Ну - түләүле мәгариф хезмәт күрсәтүләренә салымнар гамәлдәге салым законнары нигезендә билгеләнә);

Ср - мәгариф учреждениесенең матди базасын үстерүгә акчалар (табыш). Алынган акчалар белем бирү процессын камилләштерүгә һәм учреждениенең матди базасын үстерүгә җибәрелә. Белем бирү учреждениесенең матди базасын үстерүгә акчалар күләме түләүле белем бирү хезмәтенең үзкыйммәтеннән 30 %ка кадәр билгеләнә.

## I. Мәгариф учреждениеләре күрсәтә торган түләүле мәгариф хезмәтләренең үзкыйммәтен исәпләү

1.1. Түләүле белем бирү хезмәтләренең үзкыйммәтен исәпләп чыгару өчен (Сс) чыгымнар аларның икътисадый эчтәлеге нигезендә түбәндәге эреләндерелгән элементлар - турыдан-туры (Рпр) һәм кыек (Ркосв) буенча төркемләнә:

$$Сс = Рпр + Ркосв.$$

1.2. Түләүле белем бирү хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле һәм аны күрсәтү процессында кулланыла торган чыгымнар турыдан-туры чыгымнарга керә. Мондый чыгымнарга керәләр:

1) мәгариф учреждениесенең педагогик персоналы хезмәтенә түләү чыгымнары (ФОТпп). Чыгымнар федераль норматив хокукый актлар, Татарстан

Республикасының һәм Биектау муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

Мәгариф учреждениеләренең педагог персоналының хезмәт хакына чыгымнар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хезмәт хакы ставкалары (вазыйфаи окладлар), тариф ставкалары, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

- хезмәт өчен түләү мәсьәләләрен җайга сала торган Татарстан Республикасы һәм Биектау муниципаль районы федераль норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары нигезендә өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр.

Хезмәт шартнамәләре яисә граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча эшләүче мәгариф учреждениесенең педагогик персоналы хезмәтенә түләү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы һәм Биектау муниципаль районы законнары нигезендә билгеләнә.

Белем бирү учреждениесенең педагогик персоналының хезмәт өчен түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ФОТпп = (СТчас+ ПР) х Кчас, монда

ФОТпп - педагогик персоналның аена хезмәт хакы.

СТчас - педагогик персоналның сәгатенә хезмәт хакы (сәгатьлек тариф ставкасы);

Кчас - түләүле белем бирү хезмәте күрсәтелгән айга сәгатьләр саны;

ПР - педагогик персонал премиясе. Педагогик персонал премиясе күләме бер сәгать тариф ставкасыннан 150% ка кадәр билгеләнә.

Педагогик персоналның хезмәт хакына чыгымнар сәгатькә, билгеләнә:

СТчас = СТ/Нвр, монда

СТ - Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турындагы нигезләмә нигезендә педагогик хезмәткәрнең хезмәт хакы ставкасы;

Нвр - норматив документлар нигезендә ставкага куелган айга эш сәгатьләре нормасы.

2) педагогик персоналның хезмәт хакына карата түләүләр (Нпп) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә һәм бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәренә чыгымнарны кертә.

Хезмәт шартнамәләре яисә граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча эшләүче мәгариф учреждениесенең педагогик персоналының хезмәт хакына түләүләр Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

3) матди чыгымнар (Мз), өстәмә белем бирү хезмәте күрсәтү процессында турыдан-туры кулланыла торган инвентарь, укыту-методик ярдәмлекләр һәм башка чыгым материаллары сатып алуга чыгымнарны үз эченә ала.

Матди чыгымнар алдагы чордагы факттагы мәгълүматларга нигезләнеп исәпләнә, ә түләүле мәгариф хезмәтләренең әлеге төре булмаганда, алдагы чорда план күрсәткечләреннән файдаланырга мөмкин.

Матди чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

М3 =Фсм/Т, монда

Фсм - өстәмә белем бирү хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган материалларның факттагы бәясе;

Т - материаллардан файдалану вакыты (ай).

4) урыннарны, корылмаларны (Ап) арендалау өчен түләү төзелгән шартнамәләр нигезендә билгеләнә.

Аренда түләве турыдан-туры өстәмә белем бирү хезмәте күрсәтелә торган биналар өчен түләнгән очракта, аренда түләве турыдан-туры кертелә. Чыгымнар, билгеле бер вакыт аралыгында түләүле белем бирү хезмәтләренең күрсәтелгән күләменә һәм өстәмә белем бирү хезмәтен кулланучыларның санына карап, үзкыйммәткә кертелә.

Турыдан-туры чыгымнар (Рпр) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Рпр = ФОТпп + Нпп + Мз + Ап.

1.3. Кыек чыгымнарга (Ркосв) түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәк булган чыгымнар төрләре керә, ләкин аларны турыдан-туры счет ысулы белән үзкыйммәткә кертергә ярамый.

Түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәткәндә кыек чыгымнар булып тора:

1) мәгариф учреждениесенең гомуми гамәлгә куелган персоналының (ФОТоу) хезмәтенә түләү җитәкчеләрнең, административ-хуҗалык, укыту-ярдәмче һәм турыдан-туры түләүле белем бирү хезмәтләрен күрсәтүдә эшләмәгән хезмәт күрсәтүче кече персоналның, өстәмә түләүләр һәм кызыксындыру характерындагы башка түләүләрне дә кертеп, хезмәт хакын үз эченә ала.

Хезмәт шартнамәләре яисә граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча эшләүче мәгариф учреждениесенең гомуми гамәлгә куелган персоналының хезмәтен түләү;

2) гомумучреждение персоналының хезмәт хакына карата түләүләр Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә һәм бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәре чыгымнарын кертә.

Хезмәт шартнамәләре яисә граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча эшләүче мәгариф учреждениесенең гомуми гамәлгә куелган персоналының хезмәт хакына түләүләр Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

3) хуҗалык чыгымнары (Рх) (мөлкәтне тоту чыгымнары, шул исәптән видеокүзәтү системаларына, саклау системаларына, АПС, КТС системаларына техник хезмәт күрсәтү, санитар-эпидемиологик хезмәт күрсәтүләргә, чыгым материалларын, юу чараларын сатып алуга һ.б. чыгымнар), коммуналь чыгымнар, биналарга, биналарга һәм корылмаларга аренда түләве.

Кыек чыгымнар алдагы елның факттагы күрсәткечләре буенча йә ресурслар белән җитәрлек тәэмин ителмәгән яисә киләчәктәге елга хуҗалык эшчәнлеге нигезендә белешмәләр булмаган очракта билгеләнә.

Әлеге чыгымнар мәгариф учреждениесенең бюджет сметасы кысаларында норматив чыгымнарга карата өстәмә рәвештә каралган;

4) башка чыгымнар (Рпроч) шулай ук алдагы елның факттагы күрсәткечләре буенча йә ресурслар белән җитәрлек тәэмин ителмәгән яисә киләчәктәге елга финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы нигезендә белешмәләр булмаган очракта билгеләнә.

Кыек чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Ркосв = ФОТоу + Ноу + Рх + Рпроч, монда:

Ркосв - түләүле белем бирү хезмәтләренең үзкыйммәтенә кертелә торган кыек чыгымнарның зурлыгы;

ФОТоу - мәгариф учреждениесенең гомумгамәлгә куелган персоналының хезмәтенә түләү;

Ноу - мәгариф учреждениесенең гомумучреждение персоналының хезмәт хакына карата түләүләр;

Рх -хуҗалык чыгымнары;

Рпроч -башка чыгымнар.

Конкрет п-нче өстәмә белем бирү хезмәтенең үзкыйммәтенә кыек чыгымнар өстәмә белем бирү хезмәтенә туры килә торган турыдан-туры чыгымнарга пропорциональ рәвештә, турыдан-туры чыгымнарның исәп-хисап коэффициенты аша кертелә (Ккр):

Ркосвп = Рпрп х Ккр, монда:

Ркосвп – п-нче өстәмә белем бирү хезмәтенең үзкыйммәтенә кертелә торган турыдан-туры чыгымнарның зурлыгы;

Рпрп - п-нче түләүле өстәмә белем бирү хезмәтенең үзкыйммәтенә кертелә торган турыдан-туры чыгымнар күләме;

Ккр - әлеге өстәмә белем бирү хезмәтенең үзкыйммәтенә кертелә торган турыдан-туры чыгымнарга пропорциональ рәвештә кыек чыгымнар коэффициенты.

Кыек чыгымнар коэффициенты (Ккр) алдагы чорның факттагы күрсәткечләре буенча йә (ресурслар белән җитәрлек тәэмин ителмәгән яисә алдагы чор өчен белешмәләр булмаган очракта) киләсе елга эш планы нигезендә түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Ккр =(ФОТоу+Ноу+Рх+Рпроч) / Рпр.

## II. Өстәмә белем бирү хезмәтләренә бәяләр дискриминациясе

2.1. Түләүле белем бирү хезмәтләренең төрле төрләренә ихтыяҗ формалашу үзенчәлеген, аның вакыт белән тигез булмавын исәпкә алып, белем бирү учреждениеләре, ихтыяҗның үзгәрүенә карап, бер үк хезмәт күрсәтүгә (бәя дискриминациясенә) төрле тарифлар билгели ала.

2.2. Икътисадый эффект укучыларны күбрәк җәлеп итү, түләүле белем бирүнең азрак престижлы төрләрен дотацияләү исәбенә ирешелсә, түбән бәяне куллану рөхсәт ителә, әгәр икътисадый файда бәяләр аермасын бер үк вакытта өстәмә белем бирү хезмәтләренә тарифлар арту исәбенә бәядәге аерманы арттырып бүлү исәбенә киметүче коэффициентларны куллану исәбенә ирешелә.

2.3. Түләүле белем бирү хезмәтләрен экстернат рәвешендә, шулай ук бәйрәм (ял) көннәрендә, төнлә (ял көне төркемнәренә, озайтылган көнгә, балаларга төнлә булу) хезмәт күрсәтүләр бәясенә арттыра торган коэффициентлар кулланыла ала.

2.4. Түләүле белем бирү хезмәтенең бәясе, дискриминация коэффициентын исәпкә алып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Суд = Суп х К, монда:

Суд- дискриминация коэффициентын исәпкә алып, бер кулланучыга

исәпләгәндә түләүле белем бирү хезмәтенең бәясе;

Суп- бер кулланучыга исәпләгәндә түләүле белем бирүнең үзкыйммәте;

Кд - дискриминация коэффициенты.

Бәя дискриминациясе коэффициентлары белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәгариф бүлеге» МКУ белән килештерелгән түләүле белем бирү хезмәтләрен оештыру турындагы боерыкта чагылдырыла.

III. Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәткәндә салым салу

Тарифларда исәпкә алына торган салым түләүләренең күләме гамәлдәге салым законнары (федераль, региональ һәм җирле) белән билгеләнә.

«КИЛЕШТЕРЕЛДЕ»
Район башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары – «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы
«______»____________, 201__ел
М.У.

ТҮЛӘҮЛЕ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮГӘ ТАРИФ ИСӘП-ХИСАБЫ

| | |
|---|---|
| Учреждение исеме | |

| | |
|---|---|
| Хезмәт күрсәтү исеме | |
| Хезмә күрсәтү чоры | |
| Айга дәресләр саны, (барлыгы), шул ис.: | |
| 1 дәрес | |
| Дәрес исеме | |
| Айга дәресләр саны, (барлыгы) | |
| Бер дәреснең дәвамлылыгы (мин.) | |
| 1 хезмәткәр | |
| Педагогик хезмәткәрнең квалификация категориясе | |
| Хезмәт хакы ставкасы күләме (сум/ай) | |
| Премия күләме (0-150%) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 1 ставкага эш нормасы (академик сәг./айга) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 1 хезмәткәр буенча туры ФОТда чыгымнар (сум/ай.) | |
| 1 хезмәткәр | |
| Педагогик хезмәткәрнең квалификация категориясе | |
| Хезмәт хакы ставкасы күләме (сум/ай) | |
| Премия күләме (0-150%) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 1 ставкага эш нормасы (академик сәг./айга) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 2 хезмәткәр буенча туры ФОТда чыгымнар (сум/ай.) | |
| Ике хезмәткәр буенча туры ФОТда чыгымнар (сум/ай.) | |
| Төркем күләме (кеше.) | |
| Туры ФОТта бер укучыга чыгымнар (сум/ай) | |
| 2 дәрес | |
| Дәреснең исеме | |
| Айга дәресләр саны (барлыгы) | |
| Бер дәреснең дәвамлылыгы (мин.) | |
| 1 хезмәткәр | |
| Педагогик хезмәткәрнең квалификация категориясе | |
| Хезмәт хакы ставкасы күләме (сум/ай) | |
| Премия күләме (0-150%) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 1 ставкага эш нормасы (академик сәг./айга) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 1 хезмәткәр буенча туры ФОТда чыгымнар (сум/ай.) | |
| 2 хезмәткәр | |
| Педагогик хезмәткәрнең квалификация категориясе | |
| Хезмәт хакы ставкасы күләме (сум/ай) | |
| Премия күләме (0-150%) | |
| Нигезләмә (НХА) | |
| 2 хезмәткәр буенча туры ФОТда чыгымнар (сум/ай.) | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ике хезмәткәр буенча туры ФОТда чыгымнар  (сум/ай.) | | | | |
| Төркем күләме (кеше.) | | | | |
| Туры ФОТта бер укучыга чыгымнар (сум/ай) | | | | |
| ТУРЫДАН-ТУРЫ ЧЫГЫМНАР | | | | |
| Туры ФОТта бер укучыга гомуми чыгымнар (сум/ай) | | | | |
| Туры ФОТта бер укучыга гомуми чыгымнар, отпускныкыларны исәпкә алып (сум/ай) | | | | |
| Хезмәт өчен түләүгә (30,2%) (сум/ай) түләүләр | - | | | |
| Бөтен төркемгә матди чыгымнар (сум/ай) | | | | |
| Чыгымнар исеме | Саны (данә) | Бер. Өчен бәя (сум) | Куллану срогы (ай) | Айга бәясе, (сум) |
| | | | | |
| | | | | |
| бер укучыга матди чыгымнар (сум/ай) | | | | |
| Бөтен төркемгә аренда түләве (сум/ай) | | | | |
| Бөтен төркемгә аренда түләве (сум/ай) | | | | |
| Йомшак инвентарь тузуы бөтен төркемгә (сум/ай) | | | | |
| БАРЛЫГЫ: турыдан-туры чыгымнар (сум) | | | | |
| КЫЕК ЧЫГЫМНАР | | | | |
| Түләүле хезмәтләр хисабына (бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары буенча) тулаем алганда учреждениеләр буенча фактик кыек чыгымнар (мәгълүматлар булмаган очракта - план чыгымнары ), шул ис. | | | | |
| -ФОТ (АУП) (сум) | | | | |
| -ФОТ (башка персонал) (сум) | | | | |
| - ФОТка түләү (АУП)(сум) | | | | |
| Материаль чыгымнар (сум) | | | | |
| Амортизация (сум) | | | | |
| Коммуналь хезмәтләр (сум) | | | | |
| Мөлкәт тоту буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр (сум) | | | | |
| Транспорт хезмәтләре (сум) | | | | |
| Элемтә хезмәтләре (сум) | | | | |
| 2014 елгы түләүле хезмәтләр исәбенә тулаем гамәлгә ашыру буенча фактик турыдан-туры чыгымнар (бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары буенча) (мәгълүматлар булмаган очракта - план чыгымнары), шул ис. | | | | |
| ФОТ (төп персонал) (сум) | | | | |
| ФОТка түләү (төп персонал) (сум) | | | | |
| Кыек чыгымнар коэффициенты | | | | |
| БАРЛЫГЫ: кыек чыгымнар (сум) | | | | |
| Тулы үзкыйммәте (сум) | | | | |

| | |
|---|---|
| Матди базаны үстерүгә акчалар (30% ка кадәр) | |
| Бер укучыга хезмәт күрсәтүнең бәясе (сум/ай) | |